**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статьи 13[1] и 21 Закона Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 марта 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 96 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 13[1] изложить в следующей редакции:

«1. Предельный возраст пребывания на государственной службе – 65 лет. Государственному служащему, достигшему предельного возраста пребывания на государственной службе, замещающему должность государственной службы категории «помощники (советники)», учреждаемую для содействия лицу, замещающему государственную должность Республики Татарстан, срок государственной службы с согласия данного государственного служащего может быть продлен по решению представителя нанимателя до окончания срока полномочий указанного лица. Государственному служащему, достигшему предельного возраста пребывания на государственной службе, замещающему должность государственной службы категории «руководители» высшей группы должностей государственной службы, срок государственной службы с его согласия может быть продлен (но не свыше чем до достижения им возраста 70 лет)

назначившими его на должность государственным органом или соответствующим должностным лицом. Государственному служащему, достигшему предельного возраста пребывания на государственной службе, замещающему должность государственной службы категории «руководители» главной группы должностей государственной службы в органах исполнительной власти Республики Татарстан, срок государственной службы с его согласия может быть продлен (но не свыше чем до достижения им возраста 70 лет) назначившими его на должность органом исполнительной власти Республики Татарстан или соответствующим должностным лицом по согласованию с Главой (Раисом) Республики Татарстан.»;

2) часть $10^1$ статьи 21 изложить в следующей редакции:

«$10^1$. В состав аттестационной комиссии в органе исполнительной власти Республики Татарстан, при котором в соответствии со статьей 26 Закона Республики Татарстан от 27 апреля 2017 года № 24-ЗРТ «Об Общественной палате Республики Татарстан» образован общественный совет, наряду с лицами, указанными в части 10 настоящей статьи, включаются представители указанных общественных советов. Общее число этих представителей и независимых экспертов должно составлять не менее одной четверти от общего числа членов аттестационной комиссии.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
03 апреля 2023 года
№ 21-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының $13^{1}$ һәм 21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^{1}$ статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яше – 65 яшь. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка ярдәм итү өчен гамәлгә куелган «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры әлеге дәүләт хезмәткәренең ризалыгы белән яллаучы вәкиленең карары буенча күрсәтелгән затның вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр озайтылырга мөмкин. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры аның ризалыгы белән аны вазыйфага билгеләп куйган дәүләт органы яисә тиешле вазыйфаи зат тарафыннан озайтылырга мөмкин (әмма ул 70 яшькә җиткәнчегә

кадәр). Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры аның ризалыгы белән, Татарстан Республикасы Рәисе белән килештереп, аны вазыйфага билгеләп куйган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә тиешле вазыйфаи зат тарафыннан озайтылырга мөмкин (әмма ул 70 яшькә җиткәнчегә кадәр).»;

2) 21 статьяның $10^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^1$. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә иҗтимагый совет оештырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органында аттестация комиссиясе составына әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән затлар белән бергә әлеге иҗтимагый советлар вәкилләре дә кертелә. Бу вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 03 апрель
№ 21-ТРЗ